январь 2025

**МБМБУ «Яңа Кенәр балалар бакчасы»**

# *Чишмә башы*

*Ананың балага биргән иң зур бүләге-тел.*




Россия президенты Владимир Путин 2026 елны Халыклар бердәмлеге елы дип игълан итте. Карар Россия җәмгыятендә милләтара тынычлык һәм дуслык әһәмиятен ассызыклый, илебездә яшәүче халыклар арасында мәдәни элемтәләрне ныгытуга ярдәм итә. Халыклар бердәмлеге елы үзара аңлашу, хөрмәт атмосферасы булдыруга, милли теләктәшлекне һәм уртак мирас өчен горурлыкны үстерүгә ярдәм итүгә юнәлтелгән. Укучыларыбыз өчен “Россия халыклары бердәмлеге елы” дигән танышу дәресе үткәрелде. клаучылар” елы бөек илебез өчен яңа ачышлар, казанышлар һәм горурлык чоры булсын!




2026 ел Татарстанда "Хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елы" дип игълан ителде. Батырлык, хезмәт кебек төшенчәләргә кечкенәдән нигез салына. Ватанпәрвәрлек рухында тәрбияләнүләре һәм төрле вакытта Ватаныбызны саклаган геройлар истәлеген саклавы бик мөһим. Батырларның бөек мирасын саклау, аларның кыюлыгын һәм хезмәтләрен өлге итеп алу, кыйммәтле тәҗрибәләренә таянып атлау — изге бурычыбыз.

"Илләребездә тынычлык урнашсын, Ватан сагында булган ир-егетләребезгә тизрәк әйләнеп кайтырга язсын!

# *Канатлы дусларыбыз өчен җимлекләр*







Иң гади җимлекне теләсә кайсы кул астындагы материалдан ясарга мөмкин. Әмма берничә төп кагыйдәне истә тоту мөһим: 1. Җимлекнең 2 тишеме булырга тиеш (кош җимлеккә керүдән курыкмсын өчен керү һәм чыгу юлы). 2. Керү һәм чыгу юлы киң булырга тиеш, кош җимлекнең эченә тыныч кына үтеп керә алсын һәм аны ташлап китсен өчен. 3. Җимлекнең түбәсе булырга тиеш, югыйсә азык кар белән күмелергә мөмкин. 4. Җимлекнең бусагасы ясалырга тиеш, азык таралмасын өчен. 5. Җимлек эленгән бауны беркетергә онытмагыз. Кошларны ашатканда берничә кагыйдәне истә тотырга кирәк: 1. Тукландыру вакытында урамда полиэтилен пакетлар, калай банкалар, тартмалар калдырмаска. 2. Бер үк урында һәм бер үк вакытта ашатсагыз, кошлар үзләре дә шул вакытка очып киләчәкләр. 3. Кошларны даими, көн саен ашатырга кирәк, әллә нигә бер ашатырга ярамый, нәкъ менә салкыннарда кошларга исән калу өчен көн саен азык кирәк.

## Кошларга нәрсә ашатып була?

Кошларны нәрсә белән сыйлап була? Орнитологлар кисәткәнчә, кошларга бернинди очракта да, тозлы, кыздырылган, ачы продуктлар ашатырга ярамый. Кошларга цитруслар (әфлисун һәм лимон), банан кабыгын бирергә ярамый. Аларны дөге һәм карабодай белән ашату килешми. Вакланган каты ак ипи бирергә мөмкин. Саф икмәк салкыннан ката, кошлар аның белән бернәрсә дә эшли алмаячак. Кара икмәк тә куркыныч - ул начар эшкәртелә (бигрәк тә салкында). Барлык вак каурыйлыларның да диярлек яраткан ризыгы - көнбагыш, алар вак һәм, әлбәттә, кыздырылмаган булыргатиеш. Акыллы кошлар орлыкны тулысынча, кабыгы белән йотмый, ә оста итеп әрчиләр. Көнбагыштан тыш, кошлар карбыз, кавын, кабак, ташкабак һәм патиссон орлыкларын, тары, миләш һәм кукуруз яраталар. Шулай ук пешкән йомырка, пешкән бәрәңге, геркулес (ләкин ботка рәвешендә түгел). Чыпчыклар тары ярата. Тукраннарны ит һәм май кисәкләре кызыксындыра. Кызылтүшләр миләш җиләкләрен яраталар. Безнең балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр дә читтә калмадылар, кошларга ярдәм иттеләр. Балалар үз куллары белән кошларга җимлек ясадылар, бу процесс аларда аеруча кызыксындыручанлык уятты. Бу баларны кошлар турында кайгыртырга өйрәтә торган яхшы традиция дә, искиткеч иҗади шөгыль дә. Бакчабыз тәрбияләнүчеләре ашарга яраклы җимлекләр – эко җимлекләр, чөнки аларны органик материаллардан ясыйлар. Мондый җимлекне, чүкеч, клей яки кадак кулланмыйча, үз кулларың белән ясап була. Нәтиҗәдә, кошларга ошаган һәм табигый тирәлектә гармонияле булып күренгән вариантлар килеп  чыга.

# Гыйнвар аена сынамышлар һәм ышанулар

· Чәүкәһәм каргалар һавада очып әйләнсә – кар явар, карга утырсалар – жылыга, агачларныңөске өлешенәкунсалар – каты суыкларга;
· Чыпчыклар чыркылдашса – жепшетә;
· Гыйнварда тукран шакылдата башласа – яз вакытыннан алда килә;
· Елның беренче ае жылы икән, яз соңара һәм май суык була;
· Ел башы суык булса, жәй эссе килә;
· Гыйнвар кар-буранлы булса, жәй көне яңгыр еш явар;
· Гыйнварның икенче яртысында кояшлы көннәр – яхшы уңышка;
· Гыйнварда озын һәм еш урнашкан боз сөңгеләре эленеп торса, уңыш яхшы булыр;
· Сукыр тычкан гыйнварда оясыннан чыкса – май салкын була;
· Гыйнварда март булса, мартта гыйнвардан курык.

## “Балачак – бергә уйнап үсәрчак”

**«Ак аю»**

Карга диаметры 4–5 метр булган әйләнә сызып, уйнаучылар шунда кереп баса. Ике бала «ак аю» итеп билгеләнә һәм әйләнәнең тышкы ягында кала. Алар, кулга-кул тотынып, әйләнә эчендә йөрүче балаларны «ятьмәгә эләктереп» йөриләр. Һәр эләккән бала уеннан чыга барып, соңыннан аюларга тоттырмаган берсе генә кала, һәм ул жиңүче була.

# Табышмаклар

Һәржир карланган,
Сулар бозланган,
Уйный жил-буран,
Бу кайчак, туган? (Кыш көне)
Тәңкә карлар сибелгән
Жир ап-акка күмелгән.
Чыршы, каен, имән
Кардан чикмән кигән.
Бу кайчак? (Кыш)

Йолдыз, йолдыз вак кына,
Яфраклары ак кына.
Өс киемеңә куна,
Тәнгә тисә су була
(Кар бөртеге)

Оча – юк канатлары,
Чаба – юк аяклары,
Тышта булса өелә,
Өйгә керсә, жәелә. (Кар)



· Телефон: 8(84366)91-1-32
422031, Республика Татарстан, Арский район, с.Новый Кинер, улица Пионерская, дом 10

*Муниципальное бюджетное дошкольное образовательное учреждение «Новокинерский детский сад» Арского муниципального района Республики Татарстан функционирует с 30 декабря 2003 года.*

**<u>График работы МБДОУ «Новокинерский детский сад":</u>**

Понедельник - с 7.00 до 17.30

Вторник – с 7.00 до 17.30

Среда - с 7.00 до17.30

Четверг - с 7.00 до 17.30

Пятница - с 7.00 до17.30

адрес официального сайта ДОУ: https://edu.tatar.ru/arsk/n-kiner/dou